РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ БАЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

*423983, РТ, Муслюмовский район, с. Баюково, ул. Советская 2*
*тел. (8-85556)3-16–38*

Баек авылы 25.10.2019 г.

## III ЧАКЫРЫЛЫШ XLIV УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 4

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»гы 28.11.2018 елның 1нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасында «Ныклы гаилә» партия проектын тормышка ашыру буенча Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсен карау нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Баек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» гы 28.11.2018 елның 1нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2 пунктларын өстәргә:

3.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә, салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән урын яисә корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яки корылмасы;

5) гараж яки машина урыны.

Салым ташламасы, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми (салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлардан һәм машина-урыннардан тыш).

2. 3,4 пунктны 4,5 пункт дип санарга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм РФ Салым кодексы нигезендә рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/baiuk.htm авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге Башлыгы** **М.Ф. Фахерлегаянов**